**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 10 октябрь № 733

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 313 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 313 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 26 сентябрь, 464 нче; 2005 ел, 1 ноябрь, 517 нче; 2005 ел, 29 декабрь, 661 нче; 2006 ел, 1 март, 87 нче; 2006 ел, 21 апрель, 198 нче; 2006 ел, 9 июнь, 293 нче; 2007 ел, 18 май, 196 нчы; 2007 ел, 25 май, 199 нчы; 2008 ел, 28 гыйнвар, 41 нче; 2008 ел, 15 июль, 509 нчы; 2009 ел, 5 июнь, 360 нчы; 2009 ел, 17 август, 551 нче; 2010 ел, 8 июнь, 440 нчы; 2010 ел, 14 октябрь, 808 нче; 2010 ел, 2 декабрь, 976 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 7 октябрь, 838 нче; 2011 ел, 15 ноябрь, 935 нче; 2012 ел, 18 гыйнвар, 25 нче; 2012 ел, 22 август, 726 нчы; 2012 ел, 24 декабрь, 1139 нчы; 2013 ел, 18 февраль, 110 нчы; 2013 ел, 7 март, 152 нче; 2013 ел, 27 апрель, 286 нчы; 2013 ел, 10 август, 558 нче; 2014 ел, 11 март, 153 нче; 2014 ел, 21 апрель, 261 нче; 2015 ел, 1 июнь, 397 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3.1 пунктта:

унбишенче абзацка «, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә террорчылык акты эшләнгән очракларда күрсәтелгән запас кысаларында товар-матди кыйммәтләр белән эш итә»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Министрлыкка беркетелгән объектларның (территорияләрнең) террорчылыктан саклануына таләпләр үтәүне оештыра һәм тәэмин итә;

террорчылыкка каршы тору чараларын гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының үзара багланышларын көчәйтү максатларында укулар үткәрүдә катнаша;

юридик затларның документларын карап тикшерә һәм намуссыз төзүчеләр гамәлләреннән (гамәл кылмауларыннан) зыян күргән гражданнар – күпфатирлы йортларны өлешләп бүлеп төзүдә катнашучылар хокукларын яклау буенча чаралар күрү өчен урнаштырыла торган коммуналь хуҗалык, төзекләндерү объектларының, гидротехник корылмаларның, күп катлы һәм (яки) җир асты машина кую урыннарының (парковкаларның), күп катлы гаражларның, индивидуаль торак йортларның һәм (яки) күпфатирлы йортларның бәяләмәләр проектлары, шулай ук Министрлык эшчәнлеге кысаларында тормышка ашырыла торган масштаблы инвестицион проектлары Татарстан Республикасы Җир кодексының $33^3$ статьясында күрсәтелгән критериеләргә һәм (яки) мондый критериеләрнең Татарстан Республикасы Президенты билгели торган сан күрсәткечләренә туры килүне килештерә.»;

3.3.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«ясалма җир кишәрлегенең планлаштырыла торган чикләрендә территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләүне законнар нигезендә тәэмин итә;

Татарстан Республикасының ике яки күбрәк муниципаль берәмлекләре (шәһәр округлары, муниципаль районнар) территорияләрендә ясалма җир кишәрлеге төзелгән очракта ясалма җир кишәрлеге төзү буенча эшләр үткәрүгә законнар нигезендә рөхсәт бирә;

Татарстан Республикасының ике яки күбрәк муниципаль берәмлекләре (шәһәр округлары, муниципаль районнар) территорияләрендә ясалма җир кишәрлеге төзелгән очракта ясалма төзелгән җир кишәрлеген кулланылышка кертүгә законнар нигезендә рөхсәт бирә яки мондый рөхсәтне бирүдән баш тарта.»;

5 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 5.7 пункт өстәргә:

«5.7. Министрлык аппаратының структур бүлекчәләре һәм хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү министр боерыгы белән раслана торган нәтиҗәлелек күрсәткечләре нигезендә гамәлгә ашырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\733.docx